| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кудашевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кодаш авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2024 Кодаш авылы № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча Әгерҗе муниципаль
районының Кодаш авыл җирлеге
Кодаш торак пунктында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башлыгы

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 21 ноябренә 13 сәг. 00 мин. гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2025 елда үзара салым акчаларын кертү өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә килешәсезме, моңа укытуның көндезге формасында белем алучы студентлар, Россия Армиясендә хезмәт узучы затлар һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтүче затлар керми:

1. Традицион күмелгән урыннарны ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү.( зиратның хуҗалык блогын урнаштыру һәм башка чыгымнар)

2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (су башнясы өчен тирән насослар һәм материаллар сатып алу, Кодаш авылында суүткәргеч ремонтлауны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу мөмкинлеген тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау һәм башка чыгымнар).

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (запас частьләр сатып алу; янгын автомашинасы йөртүчесенә хезмәт шартнамәсе буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар).

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урамнарны кардан чистарту; үлән чабу; дизель ягулыгы сатып алу; трактор йөртүчесе килешүе буенча хезмәт өчен түләү, Мәскәү урамына вак таш сатып алу һәм башка чыгымнар).

“РИЗА” “КАРШЫ”

3.Адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кодаш ав., Тукай ур., 54 йорт, авыл клубы

4.Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка чыгару, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Шакиров